МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 135/о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«20» 08 2018

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «2018 елга эш төрләре буенча Кыска чорлы планга кертелгән күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр (эшләр) бәясенең чик дәрәҗә күләмен раслау турында» 2018 елның 03 апрелендәге 58/о номерлы боерыгы белән расланган 2018 елга эш төрләре буенча Кыска чорлы планга кертелгән күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр (эшләр) бәясенең чик дәрәҗә күләменә үзгәрешләр кертү хакында

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «2018 елга эш төрләре буенча Кыска чорлы планга кертелгән күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр (эшләр) бәясенең чик дәрәҗә күләмен раслау турында» 2018 елның 03 апрелендәге 58/о номерлы боерыгы белән расланган 2018 елга эш төрләре буенча Кыска чорлы планга кертелгән күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр (эшләр) бәясенең чик дәрәҗә күләменә, түбәндәге эчтәлекле 16 бүлекне өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | **16** | **Газ белән тәэмин итү буенча инженер системасын ремонтлау** | | |
| 234.1 | 16.1 | Газ буенча эчке исәпләгеч җайланмаларны һәм бикләгеч арматура урнаштыруны исәпкә алып, газ белән тәэмин итүнең эчке трубаүткәргечен салу | м | 6 224,59 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 234.2 | 16.2 | Тышкы газ белән тәэмин итү трубаүткәргечләрен кисеменнән алып тышкы яктан урнаштыру исәпләгеченә кадәр салу (исәпләгечне исәпкә алмыйча), грунтны эшкәртеп һәм алга таба асфальт-бетон түшәмәне торгызып, юл катламын сүтеп | м | 8 653,91 |
| 234.3 | 16.3 | Бина фасады буенча газ белән тәэмин итүнең тышкы трубаүткәргечен салу, тышкы газ исәпләгечен урнаштыру бәясе белән, бинага гильзадан ике керткеч аша | м | 1 713,09 |
| 234.4 | 16.4 | Сыгылмалы шланг белән ПГ4 60х60см газ плитәләрен алмаштыру (плитә бәясе белән) | данә | 15 026,72 |
| 234.5 | 16.5 | Сыгылмалы шланг белән газ плитәләрен алмаштыру (плитә бәясеннән тыш) | данә | 2 498,53 |

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары А.М.Фроловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА